ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11. 12. 2020 г.Мензелинск № 1207

**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендә муниципаль бердәмлек хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында" 2017 ел, 24 августындагы 803 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 16 октябрендәге 935 номерлы карары нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендә муниципаль берәмлек хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2017 елның 24 августындагы 803 номерлы карарының II бүлегендәге 4 пунктына (2018 елның 18 гыйнварындагы 43 номерлы үзгәреш белән), түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

1 нче таблица

| № т/б | Хезмәткәрләрнең вазыйфалары | Вазыйфаи оклад күләме, сумнарда |
|---|---|---|
| 1 | Оешма җитәкчесе | 7 724,0 |
| 2 | Оператив дежур торучы | 7 028,0 |

2. Әлеге карар 2020 елның 1 октябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.Г.Гатинага һәм «ТР Минзәлә муниципаль районы ФБП» МКУ рәисе Л.И.Кондратьевага йөкләргә.

4. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Уставы нигезендә бастырырга (халыкка җиткерергә).

Җитәкче К. Р. Нәҗмиев